РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ СТАРОИКШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422066, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Старая Икшурма, ул. Ленина, д.17
тел. (84362) 41-6-47

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы, Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел. (84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ | КАРАР
25.03.2019 | № 10

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 14 нче ноябрендә кабул ителгән 31 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге территориясендә физик затларның милкенә салым турында" гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Россия Федерациясе Бюджет Кодексының 64 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советы

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 14 нче ноябрендә кабул ителгән 31 нче номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге территориясендә физик затларның милкенә салым турында»гы карарына (Советның 2015 нче елның 10 нчы августында кабул ителгән 19 нчы, 2015 нче елның 8 нче октябрендәге 7 нче, 2018 нче елның 3 нче августында кабул ителгән 18 нче, 2018 нче елның 21 нче ноябрендә кабул ителгән 36 нчы номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“ 3. Түбәндәге ташламаларне кертергә:

3.1. Ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йорттагы фатирга милек хокукы булган физик затларга әлеге фатирның гомуми мәйданының кадастр бәясендәге салым ставкасының процент елеше буларак билгеләнә торган суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә бирелә.

Әгәр фатир гомуми елешле милектә булса, ташламалар суммасы елешләп милектәге һәр кеше өчен аның бу фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Шул ук вакытта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый.

3.2. 18 яшькә кадәрге еч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнар-физик затлар милкенә салым түләүдән азат ителә.

Салым ташламасы салым салу объектларының чикләнмәгән санына карата бирелә.

Салым ташламасы салым салу объектларының теләсә нинди төренә карата бирелә.

Салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гариза бирәләр, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар бирергә хокуклы».

2. Әлеге карарның 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә йогынтысын җәелдерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы, авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ikshurma адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз естемә алам.

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Иске Икшермә
авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Нурмөхәммәтов